| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**06.05.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1017** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2018/2019 елгы җылыту чорын тәмамлау һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2018/2019 елгы җылыту сезонын башлау турында» 2018 елның 21 сентябрендәге 1878 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы норматив (+8°С) белән чагыштырганда югарырак күтәрелүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җылылык энергиясен төрле билгеләнештәге биналарны җылытуга җибәрүче предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә 2019 елның 6 маенда Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җылылык чорын тәмамлауны тәкъдим итәргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2018/2019 елгы җылыту сезонын башлау турында» 2018 елның 21 сентябрендәге 1878 номерлы карарының үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Тышкы һава температурасы кискен кимегән очракта, җылыту хезмәте күрсәтүче һәм биналар һәм торак биналар эчендә җылылык белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләренә хезмәт күрсәтүче предприятиеләргә җылылык җибәрүне күздә тотарга.
4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге башлыгы Д. С. Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында (http://pravo.tatarstan.ru ), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), «Зеленый Дол» һәм «Яшен Үзән» басмаларында урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников